| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.05.2026 п.г.т.Алексеевское № 194

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан кереме, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибе турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 281₁ статьясына, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы федераль законнарга, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставына туры китереп,

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан кереме, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибен (Кушымта) расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 08.04.2026 ел, № 114 «Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче затның, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесенең үз кереме, чыгымы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балиг булмаган балаларының кереме, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» карары;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 01.08.2022 № 297 «Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче затның, шулай ук муниципаль учреждение

җитәкчесенең үз кереме, чыгымы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балиг булмаган балаларының кереме, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы Нигезләмәне раслау турында» карары.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_21.05.2026_ № _194_
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан кереме, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфаларына керүче затларның, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең үз кереме, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының кермнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган мәгълүмат бирү процедурасын билгели, (алга таба – керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат).

2. Кереме, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба – эш бирүче)тапшырыла:

муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларына керүче затлар тарафыннан;

муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан-«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында мәгълүмат тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән очракта.

3. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат эшкә кергәндә муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керергә документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре турында (элекке эш урыны яисә сайланулы вазыйфаны биләү урыны буенча керемнәрен, пенсияләрен, пособиеләрен һәм башка түләүләрне кертеп), милек хокукындагы мөлкәте турында һәм үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айга кадәрге айның беренче числосына булган мәгълүматны, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшырган елга кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне һәм башка түләүләрне кертеп) хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, шулай ук аларның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм

үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына булган мәгълүматны тапшыра.

4. «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында мәгълүмат тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән очракта, муниципаль учреждение җитәкчесе мондый нигезләр барлыкка килгән елдан соң киләсе елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча,тапшыра:

чыгымнар (хисап чоры) турында мәгълүмат тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр барлык чыганаклардан (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәре турында мәгълүмат, шулай ук хисап чоры ахырына милек хокукындагы мөлкәте хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат;

чыгымнар турында (хисап чоры)мәгълүмат тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) алынган мәгълүмат, шулай ук милек хокукында булган мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында хисап чоры ахырына булган мәгълүмат.

5. Әлеге Тәртипнең 3 һәм 4 пунктларында каралган мәгълүмат Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган «БК белешмәләре» махсус программа тәэминатыннан файдаланып тутырылган форма нигезендә тапшырыла,ул Россия Федерациясе Президентының рәсми сайтында урнаштырылган, аңа сылтама шулай ук дәүләт хезмәте өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

6. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында үзе тапшырган мәгълүматта нинди дә булса мәгълүматның чагылдырылмавын яисә тулысынча чагылдырылмавын йә хаталар булуын ачыклаган очракта, ул мәгълүмат тапшырылган көннән алып бер ай эчендә әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә төгәлләштерелгән мәгълүматны тапшырырга хокуклы.

7. Әгәр муниципаль учреждение җитәкчесе керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында үзе тапшырган мәгълүматта нинди дә булса мәгълүматның чагылдырылмавын яисә тулысынча чагылдырылмавын йә хаталар булуын ачыкласа, ул төгәлләштерелгән мәгълүматны әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә тапшырырга хокуклы.

8. Әлеге Тәртип нигезендә тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүмат, әгәр федераль законнар

тарафыннан дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган мәгълүматка кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы мәгълүмат була.

9. Әлеге Тәртип нигезендә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырган зат муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына билгеләнмәгән очракта, күрсәтелгән мәгълүмат аңа язма гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла, ә язма гариза булмаганда юкка чыгарылырга тиеш.

10. Аңа бәйле булмаган хәлләр аркасында керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тапшыру мөмкин булмаган очракта, муниципаль учреждение җитәкчесе бу хакта 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 13 статьясында каралган тәртиптә һәм срокларда эш бирүченең хезмәт тәртибенә һәм мәнфәгатьләре конфликтын җайга салуга карата таләпләрне үтәү комиссиясенә хәбәр итәргә тиеш.

11. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына кергәндә затның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат тапшыруы яки тапшырмавы күрсәтелгән затны муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

12. Муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында тулы булмаган яисә дөрес булмаган мәгълүмат тапшырмау яисә тапшыру эш бирүче тарафыннан аңа ышаныч югалтуга бәйле рәвештә үзе белән төзелгән хезмәт шартнамәсен өзү өчен нигез булып тора (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясындагы 1 өлешенең 7.1 пункты).

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**